СИШӘМБЕ
5 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 3 (6725)
Аерым номеры 15 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ. ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ТАТАРСТАН АССР КОЛХОЗЧЫЛАРЫНА ҺӘМ КОЛХОЗЧЫ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНА ИПТӘШ СТАЛИННЫҢ КОТЛАУ ТЕЛЕГРАММАСЫ УҢАЕ БЕЛӘН РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘ ҮТКӘН РАДКОМИТИНГТА КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ

МӨРӘҖӘГАТЕ

ТАТАРСТАН АССР ның БАРЛЫК КОЛХОЗЧЫЛАРЫНА ҺӘМ КОЛХОЗЧЫ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНА

Кадерле иптәшләр!

«Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 100 миллион сум акча җыйган Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының колхозчыларына һәм колхозчы хатын - кызларына сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталинның котлавы һәм рәхмәте безнең йөрәкләребезне бөек шатлык белән тутыра. Иптәш Сталинның туганнарча сәламе Татарстан колхозчыларының һәм колхозчы хатын кызларының яхшы эш эшләгәнлекләре турында, кабахәт фашистларны тагын да ныграк тар мар итү өчен туганыбыз Кызыл Армиягә ярдәм итүләре турында сөйли.

Яңа ел безгә яхшы хәбәрләр алып килде. Кабахәт гитлерчы этләрне безнең данлыклы батырларыбыз кыйныйлар; торган саен ныграк һәм ныграк кыйныйлар. Совет сугышчылары алга баралар һәм туган җиребезне азат итәләр, аны фашистик шакшылардан чистарталар. Безнең данлыклы гаскәрләребез тарафыннан халык яши торган меңнәрчә пунктлар азат ителде. Фашистлар коллыгында авыр җәфа чиккән совет кешеләре безнең сугышчыларыбызны шатлыклы күз яшьләре белән каршылыйлар.

Ләкин әле безнең миллионнарча ир һәм кыз туганнарыбыз немец басып алучыларның канлы изүе астында газапланалар. Аларның кайгылары авыр, аларның җәфаланулары чиксез зур. Ачлык, җәзалау, көчләү, дар агачлары—гитлерчы кабахәтләр үзләре басып алган совет районнарына менә нәрсә алып килделәр. Анда, фронтның теге ягында, окоплар һәм чәнечкеле тимер чыбыкларның теге ягында совет кешеләре ышаналар һәм көтәләр: алар өчен азат булу сәгате, гитлерчы палачлардан үч алу сәгате киләчәк.

Бу, сагынып көткән сәгать киләчәк! Без фронтка ни дәрәҗәдә ныграк ярдәм итсәк, колхозларыбызда үз үзебезне аямыйча ни дәрәҗәдә яхшырак эшләсәк, бу сәгать шул кадәр тизрәк киләчәк.

Иптәшләр, колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар!

Тырышлыкларыбызны ун тапкыр арттырыйк! **Кызыл Армиягә яңадан яңа куәтле сугыш машиналары төзү өчен средство җыюны дәвам иттерик. Кызыл Армиягә һәм промышленность эшчеләренә үзебезнең запасларыбыздан ашлык, ит, май һәм башка продуктлар бирик.**

Иптәш Сталинның сүзләре, бу туганлык сәламе һәм рәхмәт белдерү сүзләре безне Ватан хакына, җиңү хакына яңа патриотик батырлыкларга рухландыралар. Сөекле юлбашчыбызга данлыклы эшләр белән, данлыклы фронтовиклар турында тагын да күбрәк кайгыртучанлык күрсәтү белән җавап бирик.

Безнең беренче, изге бурычыбыз—ашлык, ит, май тапшыру буенча дәүләт алдындагы барлык йөкләмәләрне үтәү. Бездә хәзерге вакытта, сугышның бу дәһшәтле көннәрендә, дәүләт алдында бурычлы булып калган бер генә колхоз да, бер генә колхозчы да булмаска тиеш. Ашлык сугуны һәм дәүләткә ашлык тапшыру планын иң кыска срокта тәмамларга кирәк.

Сугышчыларның, фронт өчен корал һәм кирәк-яраклар әзерләүче эшчеләрнең икмәкләре мул булсын өчен, без, быелгы елда югары, хәрби уңыш яулап алырга тиешбез. Ә моның өчен **язгы чәчүгә үрнәкле итеп әзерләнергә, тиеш булган барлык агротехника чараларын үткәрергә кирәк.** Беренче эш—ул **орлыкларны тулысынча әзерләү, аларны чистарту һәм чыгышларын тикшерү. Язгы кыр эшләренә кирәк булган барлык инвентарьны үз вакытында сугышчан әзерлек хәленә китерергә, тирес һәм башка ашламаларны җыярга һәм кырга чыгарырга кирәк. Атлар турында ныклап кайгыртучанлык күрсәтергә һәм мөгезле эре терлекләрне авыл хуҗалыгы эшләрендә файдалануга әзерләргә кирәк. Язгы чәчүне сугышчан төстә, кыска срокларда, агротехниканың югары таләпләре нигезендә үткәрү өчен бөтенесен дә эшләргә кирәк.**

Терлекчелекне үстерүгә карата игътибарыбызны бер генә көнгә дә йомшартырга ярамый. **Барлык яшь терлекләрне саклап калыйк һәм үстерик, терлекләрнең санын арттырыйк. Фронт өчен итне һәм майны, йонны һәм тирене мул итеп бирик.**

Иптәшләр, колхозчылар һәм колхозчы хатын кызлар! Данлыклы дата—Кызыл Армиянең 25 еллыгы якынлаша. Бу көнне хезмәттә яңа җиңүләр белән каршылыйк, фронтта көрәшүче батырларыбыз өчен бәйрәм бүләкләре әзерлик. Фашистик кеше ашаучыларны тәмам тар-мар итүне тизләтү өчен бернәрсәбезне дә кызганмыйк.

Бөтенесе дә фронт өчен, бөтенесе дә җиңү өчен!

Яшәсен безнең данлыклы Кызыл Армия!

Яшәсен даһи полководец, безнең атабыз һәм остазыбыз бөек Сталин!

Соңгы сәгатьтә

3 нче январьда безнең һөҗүм итеп баручы гаскәрләребез, кинәт удар ясап, МОЗДОК шәһәрен һәм тимер юл станциясен, шулай ук МАЛГОБЕК шәһәрен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ

* * *

4 нче январьда безнең һөҗүм итүче гаскәрләребез ЧЕРНЫШКОВСКИЙ шәһәрен һәм ЧЕРНЫШКОВ тимер юл станциясен алдылар.

Чернышковский районында зур трофейлар кулга төшерелде; шулар арасында самолетлар—17, снарядлар—2.000.000, авиабомбалар—500.000, шулай ук азык һәм хәрби милекләр тутырылган складлар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

КАЗАН

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш ДИНМӨХӘМЕТОВКА

Татарстан АССР Совнаркомы Председателе иптәш ГАФИЯТУЛЛИНГА

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты Секретаре иптәш КОЛЫБАНОВКА

Украина ССР Верховный Советы Президиумы, УССР Халык Комиссарлары Советы һәм Украина КП(б) Үзәк Комитеты, **Совет Украинасының** 25 еллыгы уңае белән туган украин халкына котлау җибәргән Татарстан АССР хезмәт ияләренә чын күңелдән рәхмәт тапшыруны үтенәләр. Бу данлыклы дата билгеләп үтелгән көндә көньяк көнбатыш фронт частьлары Украина җиренә барып керделәр. Кызыл Армия сафларында рус, украин, белорус һәм безнең илебезнең башка халыкларының уллары белән берлектә, кулга кул тотынып Украинаны азат итү өчен татар халкының данлыклы уллары да батырларча сугышалар. Украина халкы бу көннәрдә күп милләтле совет семьясының героик уллары тарафыннан үзенә күрсәтелгән туганнарча ярдәмне бер вакытта да онытмас.

Сездән алынган котлау—ул, Советлар Союзы халыкларының җимерелмәс туганлыгының һәм сталинчыл дуслыгының ачык шаһиты, Украинаны азат итү өчен көрәш эше безнең бөек Ватаныбызның барлык эшчеләренең, крестьяннарының һәм интеллигенциясенең якын һәм туган эше икәнлекне яңадан исбат итү булып тора. ССР Союзы Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының Украина Совет Социалистик Республикасы эшчеләренә, крестьяннарына һәм интеллигенциясенә иптәш Сталин һәм иптәш Молотов тарафыннан кул куелган котлавы фронтта да; тылда да сугышчан рухны тагын да күтәрде; немец басып алучыларга партизаннар ударының көчен арттыра. Украина халкы, Советлар Союзындагы барлык халыклар белән берлектә, безнең бөек юлбашчыбыз һәм полководецыбыз иптәш Сталин җитәкчелегендә, үзенең Ватан алдындагы бурычын үтәр.

УССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. ГРЕЧУХА.
УССР Халык Комиссарлары Советы Председателе Л. КОРНИЕЦ.
Украина Коммунистлар (большевиклар) Партиясе Үзәк Комитеты Секретаре Н. ХРУЩЕВ.

БОГАТОВТАН ҮРНӘК АЛЫГЫЗ

Чистай районының «Агрикультура» колхозы члены иптәш Е. Богатов хезмәт инвалиды. Аның 3 улы—Василий, Иван һәм Федор Богатовлар Ватан сугышы фронтларында батырларча сугышалар. Иптәш Е. Богатов, аның хатыны Федосия иптәш Богатова һәм аларның кызы Мария иптәш Богатова биредә, тылда армыйталмый эшләп, Кызыл Армиябезгә нык булышалар. Алар өчесе дә колхозның иң мактаулы стахановчылары булып исәпләнәләр. Алар 1942 нче елның язынннан алып хәзергә кадәр колхоз эшеннән бер генә көн дә калмадылар һәм нинди генә эшкә җибәрсәләр дә норманы бермә-бер арттырып үтәми торып кайтмадылар. Намуслы хезмәт бик яхшы нәтиҗә бирде. Богатовлар семьясы үзенең хезмәт көннәренә тик аванс тәртибендә генә дә амбар тутырып ашлык алды.

— Коммунистлар партиясе без крестьяннарны бәхетле, якты тормышка чыгарды. Колхоз безгә культуралы таза тормышны тәэмин итте. Иптәш Сталин безне тагын да яхшырак, тагын да мулрак тормышка таба җитәкләп алып бара. Немец-фашист бандалары бу бәхетле тормышыбызны җимерергә маташалар. Ләкин аларның бу явыз ниятләре бер вакытта да барып чыкмас, — ди иптәш Богатов.

Республикабызның колхозчыларына һәм колхозчы хатынкызларына иптәш Сталинның җибәргән рәхмәт телеграммасы Богатовлар семьясында тирәнтен дулкынлану тудырды. Бу семья үзенең дәүләт алдындагы 1942 нче елгы барлык йөкләмәләрен күптән үтәде инде. Дәүләткә ит тапшыру буенча 1943 нче елгы задание дә үтәлгән.

Иптәш Е. Богатов үзенең хатыны Федосия, кызы Мария белән бергәләп эшләгән хезмәт көннәренә алган ашлыктан Кызыл Армия фондына 100 пот ашлык бүләк иттеләр.

Барлык көчебезне—фронтка ярдәм итүгә!

Татарстан колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына иптәш Сталинның котлау җибәрүенә багышлап республика күләмендә үткәрелгән митингтан

«Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 100 миллион сум акча җыйган Татарстан колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына иптәш Сталинның котлау телеграммасы җибәрүенә багышлап 3 нче январьда республика күләмендә радиомитинг үткәрелде.

Митингны ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре иптәш Пазиков ачты. Ул кереш сүз сөйләде һәм Колыбанов, Динмөхәметов, Гафиятуллин иптәшләрнең иптәш Сталин исеменә җибәргән телеграммаларын һәм иптәш Сталинның җавап телеграммасын укыды.

Аннары иптәш Пазиков Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе иптәш Динмөхәметовка сүз бирде. Иптәш Динмөхәметов үзенең речен татар телендә сөйләде. Ул болай диде:

— Кызыл Армия өчен сугыш машиналары төзүгә средстволар җыю безнең илебездә бөтен халык хәрәкәте булып, совет патриотизмының куәтле демонстрациясе булып, большевистик партиянең, Ленин—Сталин партиясенең бөек һәм җиңелмәслек байрагына колхозчы крестьяннарның тирәнтен бирелгәнлекләренең демонстрациясе булып әверелде. Иптәш Сталинның котлавы безнең өчен зур һәм шатлыклы вакыйга булып тора. Шул ук вакытта ул безгә бик күп бурычлар да йөкли. Безнең бурыч—үзебезнең дәүләт алдындагы йөкләмәләребезне үтәү һәм арттырып үтәү, язгы чәчүгә сугышчан төстә әзерләнүдән гыйбарәт.

Микрофон алдында — Биектау районы, Вахитов исемендәге колхоз председателе иптәш Хисмәтуллин. Ул, колхозның дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәгәнлеге, шуның өстенә 1943 нче ел өчен 12,5 центнер ит тапшыруы турында белдерә.

—Ватан сугышы фронтларында Кызыл Армиянең зур куәт белән һөҗүм итүе һәрбер колхозчыда һәм колхозчы хатын-кызда фронтка тагын да яхшырак ярдәм итү омтылышы тудыра. Без, берничә көн эчендә генә дә, «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзү фондына 72 мең сум җыйдык һәм Дәүләт банкысына тапшырдык. Шул ук вакытта без данлыклы сугышчыларыбыз өчен бик күп җылы киемнәр дә җыеп тапшырдык.

Без, киләчәктә дә үз-үзебезне аямыйча эшләргә, фронт өчен кирәк булганнарның, ерткыч дошманны тар-мар итү өчен кирәк булганнарның барысын да эшләргә сүз бирәбез.

Аннары, Югары Ослан районы, Ворошилов исемендәге колхоз правлениесе члены иптәш Преснова чыгып сөйли.

—Мине бу митингка,—ди ул,—безнең авыл хуҗалыгы артеленең колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары, бөек Сталинның күрсәтмәләрен безнең ничек үтәвебез турында республика хезмәт ияләренә сөйләп күрсәтергә җибәрделәр.

Безнең колхоздагы работникларның күпчелеге хатын-кызлар. Без, үзебезнең ирләребезне һәм туганнарыбызны, улларыбызны фронтка—фашистик талаучыларга һәм үтерүчеләргә каршы көрәшкә җибәреп, югалып калмадык, бәлки, киресенчә, тырышып эшләп, бөтен көчебез белән фронтка—совет сугышчыларына ярдәм итәргә тотындык.

Безнең колхоз авыл хуҗалыгы эшләрен срогыннан элек үтәде һәм яхшы уңыш алды. Без дәүләт алдындагы барлык йөкләмәләрне срогыннан элек үтәдек. Дәүләткә ит тапшыру буенча без инде 1943 нче ел исәбенә дә 2 мең килограммга якын ит тапшырдык. Без колхозда удар хезмәт белән генә фронтка ярдәм итеп калмыйбыз, Кызыл Армия фондына мең литр сөт, 2 центнер ит, 48 центнер бодай, 454 центнер яшелчә тапшырдык. Кызыл Армия сугышчылары өчен бик күп җылы киемнәр җыйдык. Танклар колоннасы төзү өчен колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар 80 мең сум акча бирделәр.

Безнең колхоз 1943 нче елның язын большевикларча каршыларга әзерләнә. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт җәелдерелде, вак инвентарьлар инде ремонтланды, орлыклар чистартып салынды, хәзер агротехник чаралар үткәрәбез.

Без колхоз авылының патриотларын Кызыл Армиягә һәм оборона предприятиеләренең эшчеләренә тагын да яхшырак ярдәм итәргә чакырабыз. «Татарстан колхозчысы» исемле авиаэскадрилья төзүгә средстволар туплауны оештырыйк!

Әтнә районы, Киров исемендәге колхозның председателе иптәш Баһаветдинов үзенең чыгышында, колхозчыларның үз-үзләрен аямыйча эшләүләрен күрсәтә торган бик ачык фактлар һәм саннар китерә. Колхоз кыр эшләрен уңышлы рәвештә тәмамлаган, дәүләткә тапшырылырга тиешле 37 мең пот ашлыкны үз вакытында ашлык кабул итү пунктларына озаткан, терлекчелек продуктлары тапшыру буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәгәннән соң, колхоз, 1943 нче ел исәбенә, 50 центнер ит тапшырган.

— Безнең колхозның членнары арасында,—ди иптәш Баһаветдинов,—танклар һәм самолетлар төзү фондына 5 мең һәм 10 мең сум бирүчеләрне дистәләп санарга мөмкин. Бу фондка мин үзем 20 мең сум акча бирдем. Сугыш самолетлары төзү фондына безнең колхоз 300.000 сум һәм танклар колоннасы төзү фондына 190.000 сум акча бирде. Иптәш Сталинның котлау телеграммасы безнең барыбызны да яңа патриотик эшләргә рухландыра.

Столбище районы, «Память Ленина» колхозы председателе иптәш Полянкин колхозчыларның гүзәл эшләре турында сөйли. Колхоз дәүләткә ашлык тапшыру планын 105 процентка үтәгән, дәүләткә 655 центнер бәрәңге тапшырган (планга карата 165 процент), яшелчә тапшыру планын 1.211 процент итеп үтәгән. Шуның өстенә колхоз дәүләткә 3.807 центнер яшелчә саткан. Колхоз членнары хәзер бик тырышып язгы чәчүгә әзерләнәләр. Колхоз членнары танклар төзү фондына 120 мең сум акча биргәннәр. Иптәш Полянкин республикабызның колхозчыларын Кызыл Армиягә ярдәмне тагын да көчәйтергә, данлыклы фронтовикларга самолетлар һәм танклар тезеп бирү өчен тагын да күбрәк средстволар тупларга чакыра.

Кызыл Армия командиры орденлы иптәш Трифонов сугыш машиналары төзүгә 100 миллион сум акча җыйган Татарстан колхозчыларын һәм колхозчы хатын-кызларын кайнар рәвештә котлый.

— Кызыл Армиянең сугышчылары һәм командирлары туган җиребезне азат итү өчен үзләренең көчләрен дә, тормышларын да кызганмаячакларына сезне ышандырырга рөхсәт итегез. Ләкин тәмам җиңүгә ирешү өчен безнең тырышлыкларыбызны ун тапкыр арттырырга кирәк. Иптәшләр! Хезмәт фронтында үз-үзебезне аямыйча эшлик! Танкларның яңа колонналарын һәм самолетларның яңа эскадрильяләрен төзү өчен средстволарны тагын да күбрәк бирик! Һөҗүм итүче Кызыл Армия өчен икмәкне, итне, яшелчәне тагын да күбрәк бирик!

Советлар Союзы Герое, партизаннар отряды командиры иптәш К. ялкынлы һәм дулкынландыргыч речь белән чыкты. Ул, Белоруссия партизаннары исеменнән, Татарстанның колхозчыларын һәм колхозчы хатын-кызларын котлый.

Соңыннан, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре иптәш Колыбанов сөйләде.

—Татарстанның барлык шәһәрләренә һәм авылларына шатлыклы хәбәр таралды. «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 100 миллион сум акча җыйган өчен бөек юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталин безгә үзенең туганнарча сәламен һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен җибәрде.

Иптәш Колыбанов аннары Кызыл Армиянең уңышлары турында, аның һөҗүмгә күчүе һәм немец-фашист оккупантларга җитди ударлар ясавы турында сөйли.

— Азатлык сөюче татар халкы, Советлар Союзындагы барлык халыклар белән берлектә, немец-фашист юлбасарларга каршы чиксез нәфрәт белән чолганган. Татар халкының данлыклы уллары Ватан өчен сугышларда кыюлык һәм батырлык үрнәкләре күрсәтәләр. Безнең якташларыбыз, Советлар Союзы Геройлары Салават Кәримов, Илдар Маннанов, Виктор Григорьев, Геннадий Гобәйдуллин һәм бөек Ватан сугышының башка геройлары белән без мактана алабыз. Безнең Ватаныбызның тарихы безнең халкыбызның чит җир басып алучыларына каршы көрәшенең ачык һәм онытылмаслык үрнәкләренә бай. Безнең халкыбыз, үзенең Ватанын саклап калу өчен теләсә нинди корбаннарга барды. Безнең халкыбыз, дошманны тар-мар итүдә үзенең Ватанына булышу өчен һәрвакыт ярдәм итү юлларын тапты. Татарстан республикасының колхозчылары, танклар һәм самолетлар төзүгә средстволар җыеп, үзләренең социалистик Ватанның чын патриотлары икәнлекләрен, Совет власте тирәсенә, большевистик партия тирәсенә һәм бөек Сталин тирәсенә нык тупланганлыкларын күрсәттеләр. Совет кешеләре дошманны җиңү өчен бернәрсәләрен дә кызганмыйлар.

Буа районының «Победитель» колхозы колхозчысына—сугыш самолетлары төзүгә 50 мең сум акча биргән Андрей Никитич Алексашкинга безнең илебез, безнең сөекле Кызыл Армиябез рәхмәт әйтәләр; Апас районындагы Ишеево МТС ы тракторчысына—«Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 45 мең сум акча биргән Сафи Әхметкинга безнең илебез, безнең Кызыл Армиябез рәхмәт әйтәләр; Балтач МТС ының трактор бригадасы бригадирына — үзенең саклык акчаларыннан 30 мең сум биргән Сәфәр Бәдриевкә безнең илебез, безнең Кызыл Армиябез рәхмәт әйтәләр; Актаныш районының «Яңа тормыш» колхозы членнарына—402 мең сум акча җыйган колхозчыларга безнең илебез, безнең Кызыл Армиябез рәхмәт әйтәләр; «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 100 миллион сум акча җыйган Татарстан колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына безнең илебез, безнең Кызыл Армиябез, бөек Сталин сүзләре белән рәхмәт әйтәләр.

Сөекле юлбашчыбызның котлавы һәм рәхмәте безне яңа патриотик эшләргә, тагын да тырышып эшләргә, фронтка ярдәмне тагын да көчәйтергә чакыралар. Безнең республикабыз колхозчыларының һәм колхозчы хатын-кызларының уйлары һәм фикерләре бер генә булырга тиеш: без әле дәүләт алдында, фронт алдында бурычлы, һөҗүм итүче Кызыл Армиягә ярдәмебезне көннән-көн көчәйтергә, аңа һәм илебезгә икмәкне, итне, майны һәм башка продуктларны, шулай ук заводларга һәм фабрикаларга чималны торган саен күбрәк бирергә кирәк. Иптәшләр, колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар! Дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәү—һәрбер колхозның иң мөһим һәм иң мактаулы бурычы икәнлекне исегездә тотыгыз. Ашлык тапшыру планын иң тиз арада тәгәлләү өчен районнар, колхозлар арасындагы ярышны тагын да көчәйтик. Колхоз терлекләренең яхшы кышлауларын оештырырга, язгы чәчүгә үрнәкле итеп әзерләнергә кирәк. Бу да фронтка ярдәм итү дигән сүз. 1943 нче елгы иген уңышы турында инде хәзер үк кайгыртучанлык күрсәтергә, машиналарга һәм инвентарьга ремонт ясарга, орлыкларны әзерләргә, кышкы агротехника чараларын үткәрергә кирәк.

Бөек Сталинның котлавы безнең республикабызның колхозчыларын һәм колхозчы хатын-кызларын Кызыл Армия өчен танклар һәм самолетлар төзүгә средстволар җыюны дәвам иттерергә бурычлы итә. Безнең республикабызның Апас районы колхозчыларыннан үрнәк алырга кирәк. Алар, иптәш Сталинның котлавына җавап итеп, самолетлар эскадрильяләре төзүгә яңадан средстволар җыя башладылар һәм инде бер ярым миллион сум акча җыйнадылар.

Октябрь, Арча, Саба һәм Буа районындагы кайбер колхозлардан үрнәк алырга кирәк. Алар үзләренең дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәгәннән соң, үз запасларыннан Кызыл Армия өчен ашлык, ит, май һәм башка продуктлар җыя башладылар.

Орденлы Татарстан колхозчыларының үзләренә күрсәтелгән ышанычны аклаячакларына һәм иптәш Сталинның котлавына яңа патриотик эшләр белән җавап бирәчәкләренә без тирәнтен ышанабыз.

Радиомитинг Татарстанның барлык колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына мөрәҗәгать кабул итте.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

3 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

че январьга каршы төндә безнең кәрләр Донның урта агымы районында, линградтан көньяк - көнбатыштарак көньяктарак, Үзәк фронтта һәм ьяк Кавказда элекке юнәлешләрдә үм сугышлары алып баруны дәвам ерделәр.

* * *

талинград районында безнең гаскәрләр манга каршы ут сугышы һәм развед. лып бардылар. Шәһәрдә безнең штурм ядлары немецларны берничә бина-, 11 ДЗОТ тан һәм 18 блиндаждан еп чыгардылар. Бер ротага якын ман солдатлары юк ителде. Стали-дтан төньяк көнбатыштарак Н-че ть сугышчылары 100 дән артык гит-чыны кырдылар һәм немецларның 3 кысын сафтан чыгардылар.

* * *

Сталинградтан көньяк – көнбатыштарак көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм- дәвам иттерделәр. Дошман, совет кәрләренең алга баруын тоткарларга ылып, уңайлы чикләрдә һәм халык и торган пунктларда көчле заслоннар дыра. Безнең сугышчылар дошман лоннарын юк итәләр һәм уңышлы ештә алга баралар. Бер участокта нең частьлар румыннарның бер пехота зизиясенең калдыкларын тар мар иттеләр халык яши торган пунктта немецлар низонын чолгап алдылар. Икенче бер астокта Н-че часть танкистлары, чиге-е дошманны куып барып, немецларның дән артык солдат һәм офицерын, орудиесен, 23 автомашинасын юк итте-һәм 100 дән артык пленный алдылар.

* * *

Донның урта агымы районында безнең кәрләр, дошманның каршылык күрсә-ен җиңеп һәм аның җанлы көчләрен м техникасын юк итеп, алга киттеләр м халык яши торган күп кенә пунктлар- алдылар. Бер участокта немецларның хотасы һәм 20 танкысы безнең һөҗүм еп баручы частебызга контратака ады. Совет артиллеристлары һәм броне-йщиклары уты белән дошманның 7 тан-сы юк ителде. Дошманның башка танк-ры чигенде. Танклар ярдәменнән мәх-м калган немец пехотасы да артка генергә маташкан иде, ләкин безнең нкистлар аны куып җиттеләр һәм юк теләр. Сугыш кырында дошманның 0 гә якын үле гәүдәләре һәм күп кенә рле кораллары калды. Икенче бер частокта безнең подразделениеләр халык ши торган бер пунктны алдылар, 3 са-оход орудие, 23 автомашина һәм башка рофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр актив угыш хәрәкәтләре алып бардылар. Великие Лукидан төньяктагы районда иптәш Дьяконов командалыгындагы сугышчылар дошман оборонасының көчле рәвештә ныгытылган узелын алдылар. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

Ржевтан көнбатыштагы районда немецлар пехотасы Н-че часть саклап тора торган позицияләргә контратака ясады. Гитлерчыларның контратакасы кире кайтарылды. Сугыш кырында сафтан чыгарылган 7 танкысын калдырып, дошман элекке позицияләренә чигенде.

* * *

Нальчиктан көньяк-көнчыгыштарак безнең гаскәрләр алга баруларында дәвам иттеләр. Н-че часть сугышчылары халык яши торган бер пунктны алдылар, немецларның 3 танкысын, 2 бронемашинасын һәм 4 орудиесен кулга төшерделәр. Икенче бер участокта дошманның ике рота пехотасы тар-мар ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Минск өлкәсе партизаннарының бер отряды 10 көн эчендә дошманның 3 хәрби эшелонын юлдан чыгарган. 2 паровоз һәм 28 вагон җимерелгән. Поездлар һәлакәте нәтиҗәсендә берничә йөз гитлерчы юк ителгән. Белосток өлкәсендә хәрәкәт итүче партизан отрядлары берничә уңышлы сугыш операциясе үткәргәннәр һәм шул вакытта 1.000 гә якын дошман солдатларын һәм офицерларын кырганнар.

* * *

Түбәндә немец-фашист кабахәтләр тарафыннан Ростов өлкәсенең Малахов хуторында совет хәрби пленныйларына карата эшләнгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немецларны хутордан куганнан соң анда фашистлар тарафыннан ерткыч төстә газаплап үтерелгән 7 кызылармеецның үле гәүдәләре табылды. Гитлерчылар плен алынган кызылармеец Александр Ильич Зубковның күзләрен чукып чыгарганнар, тешләрен сындырганнар һәм битен кискәләп бетергәннәр. Немец палачлар башка пленныйларның башларын чәрдәкләгәннәр һәм йөзләрен шул кадәр гарипләгәннәр, хәтта аларны танырга да мөмкин булмады». Актка гвардия капитаны Любимов, гвардия капитаны Маскаев, гвардия капитаны Ведерников, гвардия хәрби фельдшеры Галкин һәм хуторда торучы Иванковлар кул куйганнар.

* * *

Руан районында Франция патриотлары 30 паровозны сафтан чыгарганнар һәм немецларның ике поездын бәрдерүне оештырганнар. Ләссейдә азат укчылар немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә күп кенә немец-фашист оккупантлар үлгән.

3 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

3 нче январьда безнең гаскәрләр Дон-ың урта агымы районында, Сталинград-ан көньяк-көнбатыштарак һәм көньякта-ак, Үзәк фронтта һәм Төньяк Кавказда лекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары лып бардылар. Безнең һөҗүм итеп бару-ы гаскәрләребез, кинәт удар ясап, оздок шәһәрен һәм тимер юл станция-ен, шулай ук Малгобек шәһәрен алды-ар. 1942 нче елның 27 нче декабреннан 943 нче елның 2 нче январена кадәр ткән атнада һава сугышларында һәм эродромнарда немецларның 266 самолеты, шул исәптән Сталинград районында 98 транспорт самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 122 самолет югалттык.

* * *

2 нче январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 10 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 30 га якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 2 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм бер ротага якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр дошман позицияләренә каршы артиллерия уты алып бардылар. Заводлар районында совет штурм отрядлары дошман ныгытмаларына барып керделәр һәм аларга гранаталар ыргыттылар. Икенче бер участокта безнең разведчиклар дошманның бер сугыш припаслары складын, берничә дистә ДЗОТ ын һәм блиндажларын шартлаттылар. Бер көн эчендә 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Сталинградтан төньяк көнбатыштарак безнең подразделениеләр, кинәт атака ясап, дошманның окопларын алдылар.

* * *

Сталинградтан көньяк - көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр немецларның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр. Дошман, гаять дәрәҗәдә күп югалтуларга дучар ителгәнлектән, ашыгыч рәвештә сугышка авиация частьларын кертә һәм алардан пехота сыйфатында файдалана. Дубовскоены һәм Тормосинны алган чакта совет гаскәрләре 15 склад, шул исәптән 9 сугыш припаслары складын кулга төшерделәр. Шуның өстенә сугыш припаслары төялгән бер эшелон, 1 миллион снаряд, 20 миллион патрон, 15 танк, 150 автомашина, берничә мең сапер көрәге һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Болардан тыш тагын безнең гаскәрләр 8.000 баш сыер кулга төшерделәр. Бу сыерларны немец-фашист басып алучылар чигенгән чакта гражданнар халкыннан талап алган булганнар.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр алга баруларында дәвам иттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта совет сугышчылары, дошманның тылына барып чыгып, немецларның бер артиллерия батареясын, 10 станоклы пулеметын кулга төшерделәр, бер танкны сафтан чыгардылар һәм 300 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын кырып ташладылар. Обливская районында хәрәкәт итүче, моторлаштырылган Н-че укчы часть немецларның чигенү юлларын кисте, аларның җанлы көчләрен зур югалтуларга дучар итте һәм 16 немец танкысын сафтан чыгарды. Безнең икенче бер частебыз халык яши торган 3 пунктны алды. Сугыш кырында дошманның 100 дән артык үле гәүдәләре, сафтан чыгарылган 6 танкысы, 3 орудиесе һәм 4 автомашинасы калды. Плен алынган немец солдатларының әйтүенчә, аларның дивизиясе Совет—Германия фронтына күптән түгел генә ашыгыч рәвештә Франциядән китерелгән булган.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак, дошманның бик каты каршылык күрсәтүен җиңеп, халык яши торган, ныгытылган бер пунктны алдылар. Бу пунктка килү юлларында һәм аның урамнарында дошманның бик күп үле гәүдәләре һәм кораллары калды.

Ржевтан көнбатыштагы районда дошман пехотасы, 12 танк ярдәме белән, иптәш Михайлов командалыгындагы подразделение саклап тора торган участокка контратака ясады. Сугыш нәтиҗәсендә немецлар 6 танкларын югалттылар һәм элекке позицияләренә алып ташландылар.

* * *

Төньяк Кавказда безнең частьлар дошманга каршы сугышлар алып баруны дәвам иттерделәр һәм немецларны халык яши торган берничә пункттан бәреп чыгардылар. Бу сугышларда 500 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде, дошманның 7 танкысы яндырылды, 9 танкысы зарарланды, танкка каршы ата торган 21 орудиесе, 103 ут точкасы, 13 автомашинасы һәм 6 көпшәле 3 минометы юк ителде. 15 орудие, 15 пулемет, бик күп кул кораллары һәм сугыш припаслары кулга төшерелде, шулай ук пленныйлар алынды.

* * *

Немецлар командованиесе совет гаскәрләренең Великие Лукины алулары фактын бик тырышып инкар итә. Гитлерның баш ставкасының 2 нче январь сводкасында, «Терәк пункты булган Великие Лукидагы гарнизон, бик нык каршылык күрсәтеп, советларның өзлексез кабатланган атакаларын кире кайтарды».—диелгән. Великие Лукида булган немец гарнизоны хәзер бик нык каршылык та, шулай ук хәтта пассив каршылык та күрсәтми. Менә өч көн инде бу совет шәһәрендә бер генә дә коралы немец юк. Немецлар гарнизоны, коралын ташларга теләмәгәнлектән, бөтенләй кырып бетерелде. Великие Лукины алган безнең гаскәрләр, беренче алынган саннарга караганда, 17 танк, 47 срудие, бик күп минометлар, шул исәптән 6 көпшәле 33 миномет, 136 пулемет, 400 автомашина, 42 радиостанция, бик күп ату кораллары, сугыш припаслары, азык, инженерлык милекләре һәм башка төрле хәрби милекләр тутырылган складлар кулга төшерделәр. Трофейларның санын алу дәвам итә. Бу кайберәүләргә билгеле булмаса булмас, ләкин Германия командованиесенә бик ачык билгеле. Ләкин шулай да Гитлер ставкасындагы шарлатаннар Великие Лукида булган немецлар гарнизонының язмышы турындагы дөреслекне яшерәләр. Гитлерчылар немецларның Совет—Германия фронтында чолганып алынган башка гарнизоннарындагы һәм терәк пунктлардагы солдатларның Великие Луки сабакларын искә алуларыннан һәм моннан соң кеше ашаучы Гитлер өчен мәгънәсезгә үләргә теләми башлауларыннан куркалар.

Великие Луки турында әкият чыгарып, гитлерчылар үзләренең оятсыз ялганчылар икәнлекләрен бөтен дөньяга тагын бер кат фаш иттеләр. Гитлерның баш ставкасы белдерүләрендәге бер генә сүзгә дә ышанырга ярамый, чөнки бу белдерүләр сукыр бер тиенгә дә тормыйлар.

4 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

4 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр Донның урта агымы районында, Сталинградтан көньяк көнбатыштарак һәм көньяктарак, Үзәк фронтта һәм Төньяк Кавказда элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинградның заводлар районында кечерәк штурм отрядлары һәм аерым сугышчылар дошман позицияләренә үтеп керделәр һәм гранаталар белән немецларны йортлардан һәм блиндажлардан бәреп чыгардылар. Бер төн эчендә немецларның 100 гә якын солдат һәм офицеры юк ителде, бер танкысы сафтан чыгарылды, 3 ДЗОТ ы һәм 18 блиндажы җимертелде. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр разведка алып бардылар һәм дошманның позицияләренә аттылар.

* * *

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, совет частьлары аның оборонасына үтеп керәләр. Безнең мотопехотабыз һәм танкларыбыз аеруча уңышлы хәрәкәт итәләр. Бер участокта дошман сугышка «СС» дивизиясенең 2 полкын керткән иде, ләкин ул совет гаскәрләренең кысрыклавын туктата алмады. Безнең сугышчылар төнге сугышта немецларны кысрыкладылар һәм аларны зур югалтуларга дучар иттеләр. Икенче бер участокта безнең частьлар алга барып, халык яши торган берничә пунктны немец-фашист басып алучылардан азат иттеләр.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Гвардия танк часте кинәт удар ясап, дошман оборонасы линиясен өзде һәм халык яши торган 3 пунктны алды. Дошманның тар-мар ителгән гарнизоннарының калдыклары тәртипсез рәвештә кире чигенделәр. Безнең гаскәрләр трофейлар кулга төшерделәр. Икенче бер участокта Н-че укчы часте 300 гитлерчыны кырып ташлады һәм 8 орудие, алардан 2 се самоход орудиеләр, 2 танкетка, танкка каршы ата торган 13 мылтык һәм 2 радиостанция кулга төшерде.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр, ә көчләренең бер өлеше белән алган чикләрдә ныгып урнаштылар. Иптәш Дьяконов командалыгындагы сугышчылар алга бардылар һәм дошманның берничә терәк пунктын юк иттеләр. Күрше участокта иптәш Ларцев командалыгындагы часть дошманның бик каты атакаларын кире кайтарды һәм немецларның 400 гә якын солдат һәм офицерын юк итте.

Ржевтан көнбатыштагы районда безнең гаскәрләр җирле әһәмияте булган сугышлар алып бардылар.

* * *

Моздокны алган безнең гаскәрләр төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш юнәлешләрдә дошманны куып баруда дәвам иттеләр һәм халык яши торган тагын берничә пунктны немец басып алучыларыннан азат иттеләр. Дошман зур югалтуларга дучар ителә. Бер участокта немецларның 700 солдат һәм офицеры юк ителде. Төнлә белән безнең гаскәрләр тарафыннан алынган бер станица өчен барган сугышларда немецларның 8 танкысы сафтан чыгарылды. 4 орудие, 8 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Кырымда хәрәкәт итүче партизаннар отряды румыннарның 70 кә якын солдатларыннан торган бер группага кинәт һөҗүм ясаган. Совет патриотлары 14 румынны кырып ташлаганнар, ә калганнарын качарга мәҗбүр иткәннәр. Бу отрядның берничә партизаны немецларның зенит орудиеләре өчен запас частьлар һәм төгәл приборлар белән килә торган автомашинасын юк иткәннәр. Автомашинаны алып бара торган солдатлар кырып ташланганнар. Кырымдагы икенче бер отрядның партизаннар группасы халык яши торган бер пункттагы заставага һөҗүм иткән һәм немецларның солдат һәм офицерларын үтереп бетергән.

* * *

Туапседан төньяк-көнчыгыштарак Словакиянең моторлаштырылган дивизиясендәге «Давид» полкының бер солдаты Кызыл Армия ягына чыкты. Качып килгән солдат болай диде: «Күптән түгел «Давид» полкының икенче ротасы алгы позицияләргә барудан баш тартты. Рота командиры ярдәмчесе подпоручик Репарский солдатларны сафка тезде, бер зур табак кәгазь алды һәм һәрбер солдаттан сугышырга теләме яки юкмы икәнлеге турында үз кулы белән язуларын таләп итте. Кайбер солдатлар фронтка барырга теләмәгәнлекләрен яздылар. Подпоручик бу кәгазьне штабка алып китте. Бер сәгатьтән соң безнең яныбызга батальон командиры подполковник Зверин һәм полк командиры полковник Туранец алты немец белән бергә килделәр. Ротаны сафка тезеп куйганнан соң, немецлар һәрбер унынчы солдатны алга чыгардылар һәм строй алдында аларны атып үтерделәр. Солдатлардан Гордуш, Депеш һәм башкалар атып үтерелделәр».

* * *

Югославия партизаннары Благай—Мартин—Брдо районында оккупантларга каршы сугышларда 150 гитлерчыны юк иткәннәр һәм 100 винтовка, 8 пулемет һәм сугыш припаслары кулга төшергәннәр. Костайница—Сунья районында партизаннар Маяр тимер юл станциясен алганнар. Немецларның 60 солдаты плен алынган. Бер станциядә партизаннар Югославиядә көчләп мобилизацияләнгән 800 эшчене гитлерчылар Германиягә алып бара торган поездны туктатканнар. Партизаннар барлык эшчеләрне өйләренә кайтарып җибәргәннәр, ә аларны озатып барган немецларны плен алганнар.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ (Төньяк Кавказ тауларында) Рәсемдә: Н-че тау укчы отрядының сугышчылары грузин А. Палавандишвили һәм П. Крылов иптәшләр.
ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

4 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

4 нче январьда безнең гаскәрләр **Урта Дон** районында, Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак, **Үзәк фронтта** һәм **Төньяк Кавказда** элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар. Безнең гаскәрләр **Чернышковский** шәһәрен һәм **Чернышков** тимер юл станциясен алдылар.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр дошманга каршы артиллерия атышлары алып бардылар. Участоклардан берсендә артиллерия уты белән дошманның берничә ДЗОТ ы җимерелде, 2 орудиесе юк ителде һәм бер ротага якын пехотасы таркатылды. Заводлар районында безнең штурм группалары дошманның ныгытмаларын юк иттеләр. Совет сугышчылары дошманның ДЗОТ ларына һәм блиндажларына ешеренеп бардылар һәм аларны гарнизоннары белән берлектә шартлаттылар. 200 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм итүне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Моторлаштырылган Н-че часть немец гаскәрләре группасының флангысына барып керде һәм кыю атака ясап дошманны уңайлы позицияләрдән бәреп чыгарды. Чигенүче гитлерчылар 2 танк, 14 орудие, 9 автомашина, бик күп сугыш кораллары һәм сугыш припаслары ташлап калдырдылар. Сугыш кырында дошманның 300 дән артык үле гәүдәсе калды.

* * *

Урта Дон районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар. Безнең гаскәрләр Чернышковский шәһәрен һәм Чернышков станциясен алдылар. Зур трофейлар—2 миллион снаряд, 500.000 авиабомба, 17 самолет, күп санда азык складлары һәм хәрби милек складлары кулга төшерелде. Безнең частьлар дошманның чолганып алынган гарнизонналары тирәсендәге боҗраларны кысуда дәвам итәләр. Немецлар үзләренең чолганып алынган гарнизоннарын коткару өчен зур көчләр ташладылар. Дошманның танклары һәм пехотасы берничә тапкыр контратакалар ясады, ләкин безнең артиллериянең давыллы уты астында артка тәгәрәде. Сугыш кырында дошманның 1.000 нән артык үле гәүдәләре калды. Немецларның 24 танкысы җимертелде һәм яндырылды.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр көчләренең бер өлеше белән һөҗүм сугышлары алып бардылар, ә калган участокларда үзләре алган позицияләрен ныгыттылар. Великие Лукида көньяк-көнбатыштарак Н-че частьның сугышчылары халык яши торган бер пунктка бәреп керделәр һәм анда урам сугышлары алып баралар. 2 орудие, 8 пулемет һәм 3 миномет кулга төшерелде. Ржевтан көнбатыштарак районда безнең подразделениеләр дошман пехотасының вак группаларының берничә атакасын кире кайтардылар.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр һөҗүмне җәелдерделәр. Халык яши торган зур бер пункт өчен булган сугышларда дошманның 300 солдаты һәм офицеры кырып ташланды. Бер танк, 5 автомашина һәм 20 станоклы пулемет кулга төшерелде. Халык яши торган икенче бер пункт районында совет сугышчылары сугыш припаслары тутырылган 2 склад, бер азык склады, 43 автомашина, 6.000 снаряд, 500 мина, 4 радиостанция һәм башка хәрби милекләр кулга төшерделәр.

* * *

Витебск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды дошманның 8 эшелонын юлдан чыгарып аударган. Һәлакәтләр вакытында 92 вагон, 16 цистерна һәм 48 платформа җимертелгән. Актив сугыш хәрәкәтләренең бер ае эчендә бу отрядның партизаннары шуның өстенә тагын 3 танк җимерткәннәр, 52 автомашина яндырганнар, шоссе юлындагы 11 күперне шартлаткаңнар, 17 километр озынлыкта телефон һәм телеграф элемтәсе линиясен кискәннәр. Витебск партизаннарының икенче бер отряды шоссе юлларында засададан торып 200 дән артык гитлерчыны кырып ташлаган.

* * *

3 нче январьда Гитлерның баш ставкасы түбәндәгеләрне хәбәр итте: «Германия частьлары яңа елны Терек районында зур атакалар белән башладылар. Большевикларның барлык контратакалары безнең частьларның каршылыгына очрап җимерелде». Гитлерчы идарәчеләрнең бу мактанчык лыгырдавы чынбарлыкка ачыктан-ачык каршы килә. Немец гаскәрләре яңа, 1943 нче елны күп кенә фронтларда, шул исәптән Терек районында да, тиз рәвештә, ләкин артка таба хәрәкәт итү белән башладылар. Яңа, 1943 нче елның беренче көннәрендә үк инде совет гаскәрләре Моздок, Малгобек шәһәрләрен һәм халык яши торган дистәләрчә башка пунктларны алдылар. Кызыл Армиянең ударлары астында, халык яши торган пунктларны бер бер артлы калдырып, гитлерчылар көнбатышка таба тәгәрәгәндә, немец гаскәрләренең ниндидер хыялый «зур атакалары» турында сөйләү көлке түгелме соң!

Шул ук 3 нче январьда Германиянең информация бюросы Гитлерның баш ставкасыннан Германиянең сугыш сводкасын тапшырды. Анда болай диелә: «Калугадан көнбатышка таба уңышлы һөҗүм операциясенең барышында дошманның бер батальоны, 95 ут точкасы һәм ДЗОТ лары юк ителде, пленныйлар алынды». Бу белдерү дә шулай ук гитлерчыларның гадәттәге ялган лыгырдавы гына. Калуга күптән инде совет гаскәрләренең тылында тора. Калугадан көнбатышта, Совет Информбюросы моннан элек хәбәр иткәнчә, элеккечә тынлык хөкем сөрә. Монда соңгы көннәрдә немец гаскәрләре дә, совет гаскәрләре дә бернинди дә сугыш операцияләре үткәрмәделәр.

Германия армиясе 1943 нче елны чигенү белән, ә гитлерчы ставка—ялганнарның яңа агымы белән башлады. Гитлер ставкасының шул кадәр ахмак, шул кадәр ялган уйдырмалары гитлерчы идарәчеләрнең үзләренә каршы борылалар һәм аларны бөтен дөнья алдында көлкегә калдыралар. Бу инде чыннан да, «бер бәянең чүлмәк төялгән йөкне җигерү белән мактануына» охшый.

СВОДКА
ТАТАРСТАН АССР КОЛХОЗЛАРЫНДА БАШАКЛЫ АШЛЫКЛАРНЫ СУГУНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА
1943 нче ЕЛНЫҢ 1 нче ЯНВАРЕНА
(Планга карата процентларда)

РАЙОННАР	ҮТӘЛЕШ	РАЙОННАР	ҮТӘЛЕШ
1. Тәкәнеш	100,0	35. Биектау	92,2
2. Юдино	100,0	36. Кызыл Армия	92,2
3. Әлки	100,0	37. Бондюг	92,0
4. Акташ	99,8	38. Буа	92,0
5. Саба	99,7	39. Чүпрәле	91,6
6. Апас	99,6	40. Октябрь	91,2
7. Чистай	99,6	41. Тәтеш	91,2
8. Алабуга	99,5	42. Бөгелмә	90,6
9. Биләр	99,4	43. Кызыл юл	90,3
10. Тәмте	98,6	44. Лаеш	90,1
11. Кузнечиха	98,4	45. Сарман	90,1
12. Аксубай	98,1	46. Тархан	89,9
13. Заинский	97,8	47. Әгерҗе	88,9
14. Питрәч	97,6	48. Калинин	88,9
15. Яңа Чишмә	97,6	49. Баулы	88,0
16. Ворошилов	97,0	50. Балык бистәсе	87,5
17. Ширәмәт	97,0	51. Беренче Май	86,2
18. Арча	96,9	52. Теләче	86,0
19. Кама тамагы	96,5	53. Азнакай	85,4
20. Югары Ослан	96,2	54. Шөгер	85,2
21. Дөбьяз	96,1	55. Столбище	84,4
22. Чаллы	96,0	56. Актаныш	83,2
23. Чепья	95,6	57. Буденный	81,9
24. Куйбышев	95,2	58. Алексеевский	81,4
25. Балтач	95,2	59. Тымытык	80,1
26. Әлмәт	95,0	60. Мөслим	79,0
27. Мамадыш	94,6	61. Яңа Писмән	78,1
28. Красный бор	94,0	62. Ютазы	76,4
29. Этнә	93,9	63. Минзәлә	71,5
30. Кызыл йолдыз	93,3		
31. Кукмара	93,2	Барлыгы:	91,8
32. Норлат	93,0		
33. Кайбыч	92,4	1942 нче елның 25 нче	
34. Тельман	92,4	декабрена	90,5

„КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ КАКШАМАС НЫКЛЫГЫ“

Сталинградка килү юлларында совет гаскәрләренең алты атналык һөҗүменең йомгаклары турында Англия матбугаты

ЛОНДОН, 2 январь. (ТАСС). Англия газеталары Сталинградка килү юлларында совет гаскәрләренең алты атналык һөҗүме йомгаклары турында Совет Информбюросының белдерүен үзләренең беренче битләрендә иң күренекле урыннарда басып чыгардылар.

Бер үк вакытта матбугат һәм радио Совет гаскәрләре тарафыннан Великие Луки шәһәренең һәм тимер юл узелының алынуын киң рәвештә яктырталар.

«Дейли телеграф энд Морнинг пост» газетасы болай яза: «1943 нче елда җиңүне өмет итәргә җитди нигезләр бар. Совет гаскәрләренең сугыштагы уңышлары иң беренче чиратта шуңа нигез булып тора».

Бу газета үзенең баш мәкаләсендә болай яза: «Совет гаскәрләре һөҗүменең бик яхшы итеп оештырылуы, операцияләрне эшләүдә тотнаклылык һәм билгеләнгән планнарны үтәүдә кискенлек, Черчилльнең премьер Сталинга биргән характеристикасы дөрес икәнлекне тагын бер тапкыр күрсәтә. Черчилль аны баһадир юлбашчы дип атаган иде. Узган елны руслар сугышның төп авыр йөген үз җилкәләрендә алып бардылар. Моның өчен аларга тиешле бәяне бирергә кирәк. 1942 нче елда безнең тарафтан күрсәтелгән сокланууга 1943 нче елда руслар белән ярышу өстәлер».

АФИ агентлыгының язуына караганда, Совет гаскәрләре тарафыннан Великие Лукиның алынуы гаять зур әһәмиятле вакыйга булып тора, чөнки Великие Луки немецларның оборона системасында зур роль уйнаган. Великие Лукиның алынуы немецларның коммуникацияләренә җитди куркыныч китерә.

«Ньюс кроникл» газетасы Каммюнгесның мәкаләсен урнаштырды. Ул болай яза: «Русларның һөҗүме дәвам иткән вакытта һәм Англиянең 1 нче һәм 8 нче армияләре күчәр державаларның Африкадагы барлык көчләрен юк итүгә юнәлдерелгән бурычларын үтәү белән шөгыльләнгән вакытта, без Европада икенче фронт турында Москвадан искә төшерүләрне аз ишетербез. Ләкин әгәр дә икенче фронтның ачылуы бик озакка сузылса, без бу темага үз союзникларыбызның сүзләрен яңадан ишетербез һәм бу сүзләр кискен төстә булырлар. Бу турыда шикләнмәскә мөмкин».

БЕРЛӘШКӘН МИЛЛӘТЛӘР ДЕКЛАРАЦИЯСЕНӘ БЕР ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН РУЗВЕЛЬТНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ВАШИНГТОН, 2 январь. (ТАСС). 1942 нче елның 1 нче январенда берләшкән милләтләрнең декларациясенә Вашингтон шәһәрендә кул куелган иде. Шушы еллык уңае белән Рузвельт түбәндәгеләрне белдерде:

— Берләшкән илләр сугышны алып бару өлкәсендә бердәмлеккә ирештеләр һәм алар хәзерге көндә сугыштан соңгы проблемаларга карата да берләшеп эшләүгә һәм тынычлык чорында гомуми тырышлыкларны дәвам иттерергә омтылалар.

Хәзерге көндә өч бурычны хәл итәргә кирәк булачак: цивилизациягә бандитлык һөҗүмен тулысынча юк иткәнгә кадәр басым ясауны дәвам иттерергә; варварлык көчләренә кайчан булса да яңадан йөгәненнән ычкынырга мөмкинлек бирмәү өчен илләр арасындагы мөнәсәбәтләрне оештырырга; кешелек дөньясына тынычлык һәм азатлык шартларында цивилизация уңайлыкларыннан файдаланырга мөмкинлек бирү өчен хезмәттәшлек итәргә.

Матбугат вәкилләре белән беседасы вакытында Рузвельт, бөтен дөньяда сугышның кабатлануына мөмкинлек бирмәү хәзерге вакытта иң әһәмиятле максат булып торганлыгын күрсәтте. Рузвельт болай диде: «Солых ясалгач, безнең алдыбызда бик күп бурычлар килеп чыгачак. Сугышка кадәр булган чордагы иске куркынычка кире кайтмас өчен, берләшкән илләр берләшкән хәлдә калырга тиешләр, һәм мин уйлыйм, алар шулай булып калырлар».

ГЕРМАНИЯДӘ ҺӘМ АВСТРИЯДӘ МАССОВЫЙ КУЛГА АЛУЛАР

ЛОНДОН, 3 январь. (ТАСС). «Таймс» газетасының Германия чигендәге хәбәрчесенең язуына караганда, соңгы вакытта Германиядә һәм Австриядә яңадан бик күп кешеләрне кулга алулар башланган. Гестапо һәм полиция бераз гына «шикле» булган кешеләрне дә тотып алалар һәм төрмәгә ябалар. Соңгы өч атна эчендә концентрация лагерьларына ябылган берничә йөз тоткынны каядыр алып киткәннәр һәм аларның язмышлары турында берни дә билгеле түгел. Тик Мюнхен шәһәрендә генә дә соңгы вакытта бер меңнән артык кеше кулга алынган. Австриядә Германиягә каршы оппозицияне бастыру теләге белән гестапо «ышанычсыз булган барлык кешеләрне» кырып бетерә. Венада регуляр рәвештә атнага ике тапкыр күп кенә кешеләрне үлем җәзасы биреп үтерәләр.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 805 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 21